Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
2) Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы;
3) Шәһәр төзелеше регламентлары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Гавами тыңлаулар 2026 елның 25 августыннан 2026 елның 14 сентябренә кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Иске Иштирәк, Бәкер, Ялтау авылларында үткәрелә.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының экспозициясен, гавами тыңлауларда карау өчен, авыл җирлеге администрациясе бинасында 2026 елның 01 сентябреннән ачарга:
- Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 й.;

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 2026 елның 01 августыннан 2026 елның 14 сентябренә кадәр

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Экспозиция эше барышында «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча кертергә тәкъдим итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 йорт яисә Guzel.Sharapova1@tatar.ru , 2026 елның 11 сентябренә кадәр, яисә 2026 елның 11 сентябрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында катнашучыларны исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып кую юлы белән.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

2026 елның 11 сентябре 16.30 сәг. адрес буенча: Бәкер авылы, Тау урамы, 4 нче йорт;

2026 елның 11 сентябре 17.00 сәг. адрес буенча: Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 нче йорт, авыл мәдәният йорты;

2026 елның 11 сентябре 17.30 сәг. адрес буенча: Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 нче йорт;

2026 елның 1 сентябренә кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 нче йорт; Бәкер авылы, Тау урамы, 38 нче йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 нче йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы — Шәрәпова Г.Р.